**СОВЕТ**
**Азевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Азево авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2023 Азево авылы № 38-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 20.11.2017 елның 32-2 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Азево авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 20.11.2017 елның 32-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 %.».

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Җир салымы турында» 20.11.2017 елның 32-2 номерлы Азево авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге Советының 12.10.2023 елның 35-1 номерлы карарының 1 пунктындагы 1.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы В.С.Семенов